**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 2 ноябрь

№ 830

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган Татарстан Республикасы оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 ел, 8 июнь, 373 нче карары белән расланган Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыруда катнашучы коммерциягә карамаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга республика конкурсы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган Татарстан Республикасы оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 ел, 8 июнь, 373 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 28 декабрь, 890 нчы; 2010 ел 21 сентябрь, 749 нчы; 2011 ел, 29 июль, 606 нчы; 2012 ел, 9 июнь, 500 нче; 2013 ел, 28 июнь, 444 нче; 2014 ел, 5 июнь, 380 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 734 нче; 2014 ел, 18 октябрь, 769 нчы; 2015 ел, 21 сентябрь, 693 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыруда катнашучы коммерциягә карамаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга республика конкурсы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Конкурс номинацияләре исемлеген билгеләгәндә грант бирүче караган очракларда, Дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган оешмалар реестрында торган, наркотикларга бәйле затларны тернәкләндерү һәм ресоциализацияләү милли системасының төбәк сегментына керә торган коммерциячел булмаган оешмаларга конкурста аерым социаль әһәмиятле юнәлешләр буенча катнашырга рөхсәт ителә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\830.docx